БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«16» 09 2024 ел

**КАРАР**

№ 227

Балтач районы Башкарма комитетының 2011 елның 06 ноябрендәге «Хезмәт өчен түләү Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнүче Балтач муниципаль районы бюджетыннан финанслонучы оешма хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турындагы» 660 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 05 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011елның 14 июнендәге «Хезмәт өчен түләү Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнүче дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 477 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы 731 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе карар бирә:

1. Балтач район башкарма комитетының 2011елның 30 июнендәге «Балтач муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган оешмаларның Бердәм тариф челтәре нигезендә Хезмәт хакы алучы хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 660 номерлы карарына (Балтач район башкарма комитетының 2011елның 29 октябрендәге 1170 номерлы, 2012 елның 28 ноябрендәге 1619 номерлы, 2013 елның 25 октябрендәге 219 номерлы, 2015елның 11 ноябрендәге 411номерлы, 2016 елның 29 июлендәге 194 номерлы, 2017 елның 15 августындагы 217 номерлы, 2017 елның 29 декабрендәге 298 номерлы, 2022 елның 21 гыйнварендәге 45 номерлы, 2022 елның 30 декабрендәге 372 номерлы, 2024 елның 15 маендагы 144 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән ) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 пунктның беренче абзацында «2024 елның 1 июленнән» сүзләрен төшереп калдырырга;
- карарның 1 нче кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« Балтач район
башкарма комитеты җитәкчесенең
2011 елның 30 октябрендәге
660 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлар)

| Бердәм тариф челтәре өчен түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлар), сумнар |
|---|---|---|
| 1 | 1,00 | 21 200 |
| 2 | 1,0114 | 21 442 |
| 3 | 1,0233 | 21 694 |
| 4 | 1,0346 | 21 934 |
| 5 | 1,0473 | 22 203 |
| 6 | 1,0595 | 22 461 |
| 7 | 1,0728 | 22 743 |
| 8 | 1,0855 | 23 013 |
| 9 | 1,0983 | 23 284 |
| 10 | 1,1119 | 23 572 |
| 11 | 1,1251 | 23 852 |
| 12 | 1,1393 | 24 153 |
| 13 | 1,1535 | 24 454 |
| 14 | 1,1675 | 24 751 |
| 15 | 1,1823 | 25 065 |
| 16 | 1,1973 | 25 383 |
| 17 | 1,2124 | 25 703 |
| 18 | 1,2280 | 26 034 |

Искәрмә. Җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (оклады) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладыннан) 1 - 2 разрядка түбәнрәк итеп билгеләнә.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов